**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**30 октябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларныц тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Тымытык авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында янгын техникасын карап тоту (машина йөртүчеләрнец хезмәт хакын килешү буенча түләү, запчастьләр сатып алу);
- Тымытык авылында «Халыкара хатын-кызлар көне» «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», инвалидлар декадасы, «Яца ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылында лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;
- Тымытык авылында Нефтьчеләр ур., Пушкин ур., Мәктәп ур., Вахитов ур., Полевая ур., буенча вак таш җәелгән юлларны профильләштерү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылы территориясен механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү;
- Тымытык авыл мәдәният йортында өлешчә косметик ремонт;
- Тымытык авылында Вахитов-Пушкин урамнарындагы күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Тымытык авылының Тельмана урамы, Ленин урамы зиратларында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева